**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 октябрендәге 4352 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 6 декабрендәге 10802 номерлы «Җитәкчеләрне һәм кандидатларны Казан шәһәренең муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчесе вазифасына аттестацияләүне уздыру тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 51 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон нигезендә Җитәкчеләрне һәм кандидатларны Казан шәһәренең муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчесе вазифасына аттестацияләү тәртибен төгәлләштерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 6 декабрендәге 10802 номерлы карары белән расланган Җитәкчеләрне һәм кандидатларны Казан шәһәренең муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчесе (директоры, мөдире) вазифасына аттестацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.1. Вазифага куела торган квалификация таләпләренә кандидатларны аттестацияләү хезмәт килешүе төзегәнчегә кадәр, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениесе җитәкчесе вазифасында хезмәт эшчәнлеге барышында өч елга бер мәртәбә уздырыла»;

1.2. 3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кандидат тарафыннан аттестация үткәрү турындагы гаризага түбәндәге документлар беркетеп бирелә: шәхесне таныклый торган документның күчермәсе; хезмәт кенәгәсенең һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документның күчермәсе; белем алу турындагы документларның күчермәләре; соңгы өч елда квалификация күтәрү (һөнәри яңадан әзерлек)

турындагы документларның күчермәләре; шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (4 номерлы кушымта); хөкемгә тартылуның һәм (яки) җинаять эзәрлекләве фактының булуы (булмавы) турында яисә реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләвен туктату турында белешмә.»;

1.3. 3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.4. Аттестация барышында аттестацияләнүчеләр түбәндәге этапларны үз эченә алган квалификация сынаулары уза:

а) аларның җитәкче вазифасында хезмәт эшчәнлеген башкаруына бәйле мәсьәләләр буенча тест уздыру;

б) формалаштырылган идарәчел компетенцияләрне ачыклау буенча кейсларны хәл итү – идарәче кейсларны (бурычларны) хәл итү формасында формалашкан компетенцияләр дәрәҗәсен бәяләү процедурасын узу;

в) идарә проектын саклау – гамәлгә ашыру вакыты кимендә өч ел булган идарә проектын халыкка тәкъдим итү»;

1.2. Тәртипнең 2 номерлы кушымтасын әлеге карарның 1 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләргә;

1.5. Тәртипнең 3 номерлы кушымтасын әлеге карарның 2 номерлы кушымтасы нигезендә редакцияләргә;

1.6. әлеге карарның 3 номерлы кушымтасы нигезендә редакциялəп, 4 номерлы кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 15 октябрендәге
4352 номерлы карарына
1 номерлы кушымта
(Форма)

_________________________________________
(аттестация комиссиясенең исеме)

кемнән: _________________________________
(җитәкче өчен – Ф.И.А., вазифасының һәм
учреждениенең атамасы;

__________________________________________
вазифага кандидат өчен – Ф.И.А.,

______________________________
(вазифаның атамасы)

# ГАРИЗА

Мине, ____________________________________________________________________
(вазифаның һәм учреждениенең исеме)
___________________________ вазифасы буенча квалификация характеристикасы таләпләренә туры килүне билгеләү максатыннан, 20___ елда аттестацияләүне сорыйм.

Үзем турында түбәндәге мәгълүматларны хәбәр итәм:

- туган көнем, ае һәм елы: _______________________________________;

- белемем (кайчан һәм нинди һөнәри белем бирү учреждениесен тәмамлаган, алган белгечлек һәм квалификация): ____________________________ ________________________________________________________________________;

- дәүләт яисә муниципаль идарә, менеджмент һәм икътисад өлкәсендәге юнәлешләр буенча өстәмә һөнәри белем (яки квалификация күтәрү курслары): ________________________________________________________________________;

- гомуми хезмәт стажы ______, шул исәптән педагогик эш стажы ________, җитәкче эше стажы _________, аттестацияләнә торган вазифада, __________;

- бу учреждениедә ________________ эшлим [яки эшләмәдем].

Хезмәт кенәгәсенең күчермәсен, дәүләт яисә муниципаль идарә, менеджмент һәм икътисад өлкәсендәге юнәлешләр буенча өстәмә һөнәри белем алу (яки квалификация күтәрү курслары) турында диплом күчермәсен, документның күчермәсен беркетәм (җитәкче вазифасына кандидатлар өчен);

- түбәндәге бүләкләрем, исемем, гыйльми дәрәҗәм, гыйльми исемем бар: ___________________________________________________________________________;

- ИКТ-технологияләргә ия булу дәрәҗәсе: югары, канәгатьләнерлек, түбән (кирәклесен ассызыкларга).

Өстәмә мәгълүмат:

1) өй телефоны: ____________________________________________;

2) эш телефоны: ____________________________________________.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1. ______________________________________________________________;

2. ______________________________________________________________;

3. ______________________________________________________________;

4. ______________________________________________________________.

Вазифа буенча квалификация характеристикасы таләпләре һәм белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре вазифасына җитәкчеләрне, кандидатларны аттестацияләү тәртибе белән таныштым.

20___ елның «____» ___________ __________________________

(имза)

________________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 15 октябрендәге
4352 номерлы карарына
2 номерлы кушымта
(Форма)

_______________________________________________________________________
(уку йортының исеме, вазифа, Ф.И.А. тулысынча)
_________________________________________________________________________
җитәкче вазифасына туры килүен билгеләү максатыннан аттестацияләү өчен

ТӘКЪДИМ ИТҮ

## I. Гомуми белешмәләр

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Туган көне (көне, ае, елы) | |
| 2 | Белеме турында белешмәләр (югары, нинди һөнәри белем бирү учреждениесен тәмамлаган, тәмамлау вакыты) | |
| 3 | Диплом буенча белгечлек | |
| 4 | Диплом буенча квалификация | |
| 5 | «Дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә», «Менеджмент», «Персонал белән идарә итү» юнәлешләре буенча белем бирү: | |
| 5.1 | әзерлек юнәлеше | |
| 5.2 | уку йортының исеме | |
| 5.3 | укуның дәвамлылыгы | |
| 5.4 | уку тәмамлану көне | |
| 6 | Идарә эшчәнлеге юнәлеше буенча өстәмә белем бирү: | |
| 6.1 | исеме | |
| 6.2 | белем бирү учреждениесенең исеме | |
| 6.3 | уку сәгатьләре саны | |
| 6.4 | тәмамлану елы | |
| 7 | Гомуми хезмәт стажы (ел) | |
| 8 | Педагогик эш стажы (ел) | |
| 9 | Бу вазифада эш стажы (ел) | |
| 10 | Бу учреждениедә эш стажы (ел) | |
| 11 | Хезмәткәрнең аттестацияләнә торган вазифага билгеләнү датасы | |

## II. Һөнәри эшчәнлектәге төп казанышлар

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. | Педагогик эшчәнлек буенча квалификация категориясе булу (исеме, бирү турында боерык датасы) | |
| 2.2. | Бүләкләре булу (исеме, елы) | |
| 2.3. | Гыйльми дәрәҗәсе булу (исеме, елы) | |

2.4. Җитәкченең һөнәри, эшлекле сыйфатларына, һөнәри эшчәнлек нәтиҗәләренә «Белем бирү оешмасы җитәкчесе» һөнәри стандарты

(квалификация характеристикасы) нигезендә формалаштырылган, нигезле, һәрьяклы һәм объектив бәя бирү (аттестацияара чор өчен) ____________________
________________________________________________________________________________

2.5. Тәкъдимнәр белән нәтиҗә ________________________________________
(били торган вазифага туры килә/туры килми дип тану мөмкинлеге турында мәгълүмат)

2.6. Кушымта – әлеге җитәкченең аттестация үткәрүгә кадәрге ике уку елы өчен әлеге җитәкче тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе боерыгы белән расланган критерийларның үтәлүе турында мәгълүмат язылган аналитик белешмә, __ биттә, 1 нөсхәдә.

«____» ______________ 20_____ел.
Казан шәһәре Башкарма комитетының
тармак структур бүлекчәсенең
вәкаләтле вәкиле _____________ ____________________
(имза) (аңлатмасы)

Тәкъдим белән таныштым, риза «___» ____________ 20_____ел.

____________________ ________________________ ________________________
( белем бирү оешмасы җитәкчесенең вазифасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Тәкъдим белән таныштым, риза түгел «___» ____________ 20_____ел.

____________________ ________________________ ________________________
( белем бирү оешмасы җитәкчесенең вазифасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

___________________

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 15 октябрендәге
4352 номерлы карарына
3 номерлы кушымта
(Форма)

_______________________________________________________________

(Казан шәһәре муниципаль белем бирү оешмасының исеме)

житәкчесе вазифасына кандидатның

**шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы**

Мин, ____________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ______________________________, паспорт сериясе ________ № _________, ______________________ бирелгән, ирекле рәвештә, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Казан шәһәре муниципаль белем бирү учреждениеләре җитәкчеләре вазифаларына җитәкче һәм кандидатларны аттестацияләүне үткәрү буенча аттестация комиссиясенә, түбәндәге шәхси мәгълүматларымны: фамилия, исем, атамның исеме, туган көн һәм туган урын, гражданлык; элеккеге фамилия, исем, атамның исеме, аларны үзгәртү вакыты, урыны һәм сәбәбе (үзгәрткән очракта); хезмәт эшчәнлеге башланганнан алып башкарыла торган эш (икенче эшне, эшмәкәрлекне яки башка эшчәнлекне дә кертеп), хәрби хезмәт; дәүләт бүләкләре, башка бүләкләр һәм аерымлык билгеләре (кем тарафыннан һәм кайчан бүләкләнгән); эш урыны һәм яшәү (тору) урыны буенча теркәлү урыны; паспорт (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), шулай ук хезмәт эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы башка шәхси мәгълүматларны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңарту, үзгәртү), аерып алуны, файдалануны, тапшыруны (бирү, алырга рөхсәт итү, блоклау, бетерү, юкка чыгару) да кертеп, аларны эшкәртүгә [автоматлаштыру чараларын яки андый чараларны кулланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәлләр (операцияләр), яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасын башкаруга] ризалыгымны бирәм.

Югарыда күрсәтелгән шәхси мәгълүматлар Казан шәһәренең муниципаль белем бирү оешмасы җитәкчесе вазифасына кандидат буларак мәҗбүри аттестация узу максатыннан эшкәртү өчен тапшырыла.

Мин шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкның әлеге ризалыкны имзалаган көннән гамәлгә керүе белән таныштым.

Үзем тапшырган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык турында кисәтеп куелдым.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык ирекле формада язылган язмача гариза нигезендә кире кайтарып алынырга мөмкин.

«____»_____________20___ ел. _______________________________

(имза)